ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ
РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК
РЕСУРСЛАР БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **Боерык**

17.07.2020 г. Казань № 202-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче һәм башка затлар тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указы нигезендә, һәм оештыру-штат үзгәрешләренә бәйле рәвештә **боерам:**

1. Кушылып бирелгән Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы мөдире О.А. Филипповага Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең 2016 елның 11 нче февраленнән 18-од номерлы «Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Ю.Б. Матвеевка йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Ю.Б.Матвеев

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2020
елның 17 нче июленнән
202-од номерлы боерыгы
белән расланган

**Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмә**

1. Әлеге нигезләмә аларга карата эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе(алга таба-Дәүләт комитеты рәисе) торган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба - граждан хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты) вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен регламентлый.

2. Вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турындагы хәбәр (алга таба –хәбәр) граждан хезмәткәре тарафыннан, әлеге Нигезләмәнең Кушымтасында китерелгән форма буенча, язма рәвештә төзелә һәм Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелә.

3. Дәүләт комитеты рәисе өч эш көне дәвамында, коррупция һәм башка хокук бозуларга профилактика ясау эше өчен җаваплы затка (алга таба - җаваплы зат) хәбәрне алдан карап тикшерү өчен җибәрә.

4. Хәбәрне алдан карап тикшерү барышында җаваплы зат, хәбәрне җибәргән граждан хезмәткәреннән, анда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алу, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрү хокукына ия.

5. Хәбәрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Җаваплы зат хәбәрне алган көннән җиде эш көне эчендә, алдан карап тикшерү барышында алынган хәбәрне, бәяләмәне һәм башка материалларны, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия рәисенә тапшыра (алга таба - Комиссия).

6. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән запросларны җибәргән очракта, хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан, хәбәр алган көннән алып 45 көн эчендә, Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан 30 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин.

7. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының

2018 елның 30 нчы свртыннан 79-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы нигезләмәгә туры китереп, Комиссия тарафыннан карала.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

___________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме, вазыйфа)
Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

Вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында
ХӘБӘР

Вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәкленең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган шартлар:
_______________________________________________________________________________.

Шәхси кызыксыну йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар:_____________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар:
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

Әлеге Хәбәрне караганда, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетындагы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм/ниятләнмим ( кирәклесенең астына сызарга).

«_» _________ 20__ел ___________________________ _________________________
(Хәбәрне җибәргән затның имзасы, имзаны чишү)